# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“17” ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №116 карары нигезендә, 2021 елның 16 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2021 елның 16 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 2021 елның 17 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2021 елның 17 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Түбән Бәрәскә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү);

2) урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

3) парк территориясен төзекләндерү һәм чистарту (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

5) Түбән Бәрәскә авылында ритуаль инвентарьларны саклый торган корылма төзү өчен материаллар сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6) бораулау һәм су алу скважинасын урнаштыру (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, комплектлау материаллары сатып алу);

7) Зеленая урамындагы күперне һәм басманы ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

8) Зеленая урамы буенча урам юлына таш җәю (вак таш сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» - 354 кеше «КАРШЫ» - 0

мәсьәләсе буенча халык җыенның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 618 (алты йөз унсигез) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 354 (өч йөз илле дүрт) кеше, бу 57,28 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 354 (өч йөз илле дүрт) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. "Сез 2022 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Түбән Бәрәскә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү);

2) урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

3) парк территориясен төзекләндерү һәм чистарту (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

5) Түбән Бәрәскә авылында ритуаль инвентарьларны саклый торган корылма төзү өчен материаллар сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6) бораулау һәм су алу скважинасын урнаштыру (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, комплектлау материаллары сатып алу);

7) Зеленая урамындагы күперне һәм басманы ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

8) Зеленая урамы буенча урам юлына таш җәю (вак таш сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)" мәсьәләсен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

Совет Нижнеберескинского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОГРН 1021606155405
ИНН 1610000476